БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабрь 2019 ел № 227

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач районы прокуратурасының 2009 елның 30 сентябрендәге 02-08-02-2019 номерлы ризасызлыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2019 елның 15 мартындагы 168 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.1. пунктында документлар исемлегеннән түбәндәге норматив актларны төшереп калдырырга:

- «Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне сату буенча конкурс үткәрү турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2002 елның 12 августындагы 585 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын;

- «Аукционда дәүләт яки муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру турындагы Нигезләмәне һәм махсус аукционда дәүләт яки муниципаль милектә булган ачык акционерлар җәмгыятьләренең акцияләрен сатуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2002 елның 12 августындагы 584 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын;

- «Гавами тәкъдим итү ярдәмендә һәм бәясен игълан итмичә генә Дәүләт яки муниципаль мөлкәтне сатуны оештыру турындагы Нигезләмәләрне раслау турында» 2002 елның 22 июлендәге 549 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын.

1.2. 6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль мөлкәтне аукционда хосусыйлаштыру һәм акционерлар җәмгыятьләренең муниципаль милектәге акцияләрен махсуслаштырылган аукционда сату үзенчәлекләре «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җайга салына».

1.3. 6.2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль милектәге мөлкәтне аукционда сатканда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары мөлкәт сату функцияләрен мөстәкыйль гамәлгә ашыралар, шулай ук үз карарлары белән «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1

пунктының 8.1 пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга милекче исеменнән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары яисә муниципаль берәмлекләр милкендәге хосусыйлаштырыла торган мөлкәтне сатуны оештыруны һәм (яисә) мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашыруны йөклиләр».

1.4. 6.2.23 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль милектәге акцияләрне махсуслаштырылган аукционда сатканда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары мөлкәт сату функцияләрен мөстәкыйль гамәлгә ашыралар, шулай ук үз карарлары белән «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декаберендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының 8.1 пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга милекче исеменнән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары яисә муниципаль берәмлекләр милкендәге хосусыйлаштырыла торган мөлкәтне сатуны оештыруны һәм (яисә) мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашыруны йөклиләр».

1.5. 6.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөлкәтне гавами тәкъдим итү ярдәмендә сатканда, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары мөлкәт сату функцияләрен мөстәкыйль гамәлгә ашыралар, шулай ук үз карарлары белән «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декаберендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының 8.1 пунктчасында күрсәтелгән юридик затларга милекче исеменнән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары яисә муниципаль берәмлекләр милкендәге хосусыйлаштырыла торган мөлкәтне сатуны оештыруны һәм (яисә) мөлкәтне сатучы функцияләрен гамәлгә ашыруны йөклиләр».

1.6. 6.2.16 пунктын төшереп калдырырга.

1.7. 9.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле 16 пунктчаны өстәргә:

«16. Әлеге Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының 8.1 пунктчасы нигезендә (хосусыйлаштырыла торган дәүләт яки муниципаль мөлкәтне сатуны милекче исеменнән оештыру өчен һәм (яки) мондый мөлкәтне сатучы функцияләрен башкару өчен юридик затлар исемлеген раслау турында карар кабул итә) дәүләт яисә муниципаль мөлкәт сатучы функцияләрен гамәлгә ашырган һәм (яисә) Россия Федерациясе Хөкүмәте, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы карарлары белән хосусыйлаштырыла торган дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне сатуны милекче исеменнән оештыру йөкләнгән юридик затка бүләкләү күләме һәм тәртибе».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында baltasi.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин